# 1. Информационная справка МБОУ “Многопрофильный лицей №187” Советского района по проведенным мероприятиям в рамках Года родных языков и народного единства за *апрель-* 2021 года

| УО | Всего учащихся в ОУ | Всего мероприятий (единиц) | Количество участников (чел.) | Доля от общего количества детей (%) |
|---|---|---|---|---|
| МБОУ «Многопрофильный лицей №187» Советского района г. Казани | 932 | 9 | 1397 | 134% |

2.

| УО | Наименование мероприятия | Количество участников | Информация о мероприятии |
|---|---|---|---|
| МБОУ «Многопрофильный лицей №187» Советского района г. Казани | Г.Тукай музеена экскурсия | 33 | 2 апрель көнне лицеебызның 5нче Г сыйныф укучылары сыйныф җитәкчесе Альбина Маликовна Файзуллина белән бергәлектә Габдулла Тукай музеена экскурсияга барып кайттылар. Г. Тукай әдәби музее һәм Казан шәһәре мәгариф идарәсе укучылар өчен «Балалар һәм яшүсмерләр өчен Г. Тукай лекцияләре атналыгы» оештырган. Чара Г.Тукайның тууына 135 ел тулуга багышланды. Әлеге экскурсияга барып кайтучы укучылар бик күп мәгълүмат туплап кайттылар. Музейның һәрбер почмагы Бөек шагыйрьгә багышланган кызыклы, мавыктыргычлы итеп уйланылып төзелгән. Укучыларны үзгә булган мөхиткә чумдырып, кызыксындырып эшләнгән программа өчен музей хезмәткәрләренә Зур рәхмәтебезне җиткерәбез. Мондый чараларны еш уздыруларына зур ышаныч белән көтеп калабыз. |
| МБОУ «Многопроф | Чүлмәк осталыгы | 14 | 7нче апрель көнне “187нче номерлы күп профильле лицей”ның укучылары туган |

| | | | |
|---|---|---|---|
| ильный лицей №187» Советского района г. Казани | | | телләр укытучысы Абакаева Ләйсән Камилевна җитәкчелегедә экскурсияга барды. Кызыл балчыктан измә ясап, әйбер ясау - элекке һөнәрләрнең берсе. Безнең дә Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елына багышлап, укучыларыбыз белән татар бизәкләрен кулланып, кызыл измәдән төрле матур савытлар ясау, элеккеге һөнәр белән таныштыру йөзеннән "ECERAMIC" клубына бардылар. Әлеге һөнәргә өйрәнү буенча укучыларга мастер-класс оештырылды. Укучылар кул белән эшләү осталыгына, аның үзенчәлекле алымнарына төшенделәр һәм кызыл балчыкның измәсеннән бик күп савыт-саба ясап булганына инандылар. Әби-бабаларыбыздан калган йола эшләре хәзерге көндә актуаль булып тора. Бу экскурсия укучылар өчен бик файдалы һәм кызык булып чыкты. |
| МБОУ «Многопрофильный лицей №187» Советского района г. Казани | Хезмәт дәресе татар халык орнаментлары белән бизәлде | 24 | 8нче апрель көнне план буенча каралган Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елына багышлап, безнең лицеебызда хезмәт дәресендә ачык дәрес үткәрделәр. Кызлар өчен хезмәт укытучысы, яшь белгеч, Надежда Сергеевна Симушина бик кызык дәрес күрсәтте. Дәреснең темасы “Машина тегүләрен үзләштерү. Татар халык бизәкләрен тегү үрнәкләренә өйрәтү". 5нче сыйныф укучы кызлары дәрестә актив эшләделәр, чөнки укытучының дәресе мавыктыргыч кызык иде, төрле тегү үрнәкләре барлыгына төшенделәр. Укытучы үзе дә дәреснең барлык технологик алымнарын кулланып, укучыларны җәлеп итәрлек итеп дәресне оештырып, дөрес методик алымнарын кулланып башкарды. Яшь белгеч булуына карамастан ул үзенең тәҗрибәсен укучыларга да җиткерде. Укытучыга алдагы хезмәт юлында уңышлар телибез. |
| МБОУ | “Тукай – мәңге | 514 | 22 нче апрель көнне, пәнҗешәмбе, |

| | | | |
|---|---|---|---|
| «Многопроф<br>ильный лицей<br>№187»<br>Советского<br>района г.<br>Казани | күңелләрдә”<br>бәйрәм-кичәсе | | лицеебызда Габдулла Тукай туган көненә һәм Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елына багышланган әдәби – музыкаль кичә булып узды. Бәйрәмне Г.Тукай шигыренә язылган “Бәйрәм бүген” дигән җыр белән ачып җибәрделәр. Аннары сүзне лицеебыз директоры Гөлнара Гаппасовна Галеева алды. Беренче сыйныфтан алып җиденче сыйныфка кадәр яшьтәге укучылар яраткан шагыйребез Габдулла Тукайның шигырьләрен сөйләделәр, аның әсәрләре буенча инсценировка курсәттеләр. Фольклор ансамбле «Заман» үзләренең матур күлмәкләрен киеп җырларын башкардылар. Кичәбезгә чакырылган кунаклар да булды. Алар: балалар һәм яшүсмерләр өчен чыгарыла торган “Ялкын” журналының баш мөхәррире Илназ Фаис улы Фазуллин, Яков Емельянова исемендәге мәдәният үзәгенең иҗат жанрлары буенча белгеч Марина Петровна Тараканова, Татарстан Республикасы сәнгать эшлеклесе, GOLDEN TIME TALENT - LONDON International Festival Халыкара конкурсы җиңүчесе, "Россиянең алтын тавышы" конкурслары лауреаты, “Татар моңы” фестиваленең лауреаты Лариса Басырова, Совет районының муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Мәгариф һәм мәгариф идарәсенең урынбасары Гүзәлия Гыйләҗ кызы Ибатуллина. Чакырылган кунаклар белән танышып үткәннән соң, аларның һәрберсенә сүз бирелде. Безнең укучыларыбызны бәйрәм белән котлап уңышлар теләделәр. Гомумән, кичәбез барлык тамашачыга да ошады, дип уйлап каласы килә. Беренче такыр сәхнәгә аяк баскан башкаручылар да үзләрен кыю тоттылар, чыгышларына сокланып карап утырдылар. Алдагы елларда да укучыларга сәхнә түрләрендә |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | чыгыш ясарга насыйп булсын, үзләренең сәләтләрен башкаларга да күрсәтерлек дәрәҗәдә булсын. Барысына да уңышлар телибез! |
| МБОУ «Многопрофильный лицей №187» Советского района г. Казани | «Виктория» исемендәге XII Халыкара балалар һәм яшүсмерләр иҗаты фестиваль-конкурсы | 14 | 19нчы апрель көнне лицеебызның «Заман» фольклор ансамбле «Виктория» исемендәге XII Халыкара балалар һәм яшүсмерләр иҗаты фестиваль-конкурсында катнаштылар. Яшь оешкан ансамбль булуына карамастан, җитәкчесе Абакаева Ләйсән Камилевна укучылар белән төрле чараларда актив катнашып йөриләр. Әлеге “Виктория” исемендәге фестиваль-конкурста да катнашып, бик күп конкурентлар арасыннан 3нче урын яулап кайттылар. Ансамбль кызлары югары дәрәҗәдә матур чыгыш ясадылар. Алар керәшен халык җыры “Җиләк җыйдым” дигән җыр әзерләгәннәр иде, тамашачы зур алкышлар белән бәяләде. Ансамбльга киләчәктә зур уңышлар телибез һәм яңадан яңа үрләр яуларга насыйп булсын! |
| МБОУ «Многопрофильный лицей №187» Советского района г. Казани | “Мин татарча сөйләшәм” акциясе лицейда | 433 | Туган телләр айлыгына багышлап лицеебыз укучылары «Мин татарча сөйләшәм» акциясе астында өндәмә-плакатлар ясап, күргәзмә ясадык. Күргәзмәдә 2-7нче сыйныф укучылары катнашты. Татарча чиста, матур, аһәңле сөйләшүгә өндәп иҗат ителгән плакатлар Һәм теленңне төрле чуар сүзләр чүпләмәү өндәмәләре барлык күргәзмәне карап узган кешеләрнең күңеленә хуп килде. |
| МБОУ «Многопрофильный лицей №187» Советского района г. Казани | Әкият” курчак театры | 34 | 23нче апрель көнне Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елына багышлап, безнең лиеебызның 3нче В сыйныфы һәм аның җитәкчесе Зилә Гыйнәтовна Муфазалова белән “Әкият” курчак театрына барып кайттылар. Укучылар “Җырла курай” дип аталган татар халык әкиятен карадылар. Театрны бинасының матурлыгына, зәвыклы бизәлешенә гаҗәпләнеп, спектакльне оста уйнаучы артисларга сокланып |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | безнең укучыларыбыз сөенеп-шатланып кайттылар. Һәм театрларга ешрак йөрергә теләүләрен җиткерделәр. Димәк “Әкият” курчак театры артистлары балаларда зур кызыксыну уята алган. |
| МБОУ «Многопрофильный лицей №187» Советского района г. Казани | Тукай әсәрләренә иллюстрацияләр | 238 | Габдулла Тукай айлыгына багышлап, шулай ук Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елына карата башлангыч сыйныф укытучысы Галия Рафиковна Булатова 1-4нче сыйныфлар арасында Габдулла Тукай әсәрләре буенча укучылар үз куллары белән ясаган рәсем конкурсы уздырды. Әлеге чарага барлык башлангыч сыйныф укучылары бик теләп катнашты, чөнки алар Татармульфильм кинокомпаниясе ясаган әсәләрне бик теләп карыйлар. Һәм үзләренең осталыкларын профессиональ рәссамчылар белщн чагыштырып карамакчы булалар. Чынлап та, рәсемнәр арасында бик оста итеп ясаучылар күренә башлады. Без, барысына да, уңышлар телибез! |
| МБОУ «Многопрофильный лицей №187» Советского района г. Казани | “Идел буе әкиятләре” | 13 | Совет районы күләмендә «Идел буе әкиятләре” дип аталган театраль түгәрәкләренең конкурсы булып узды. Әлеге конкурс Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елына багышлап оештырылган чара булып тора. Безнең 187нче лицей коллективы да катнашырга булды. Бу театр студиясының җитәкчесе Елена Анатольевна Гусева, аның белән бергәлектә укытучылар һәм укучылар коллективы конкурска “Өч кыз” дигән татар халык әкиятен әзерләделәр. Яңа гына оешкан коллектив булуына карамастан, катнашучы укытучыларыбыз һәм укучыларыбыз чын профессионал кебек уйнадылар. Сәхнәдә үзләрен чын оста артистларча тоттылар. Һәм нәтиҗәдә Диплом белән бүләкләнделәр. Без аларны бу |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | беренче чыгышлары белән тәбрик итәбез һәм киләчәктә дә яңа үрләр яулап алуларын телибез! |